Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№35 (86)

7 ноябрь 2013 ел



Влад Михневский фотосы

# КФУ химия юнәлешен көчәйтә

«Яңа химик элементлар ачу – химияне ачу дигән сүз. Димәк, Казан университеты химияне ачкан», – диде Дэвид Эдвин Льюис. *Дәвамы 2 биттә .*

## • Вакыйгалар эзеннән

КФУның Алабуга институты татар филологиясе һәм чагыштырма филология факультеты студенты **АЛИНӘ БӘДРЕТДИНОВА** «Русский стандарт» Хәйрия фондының (Санкт-Петербург) **«ТАЛАНТЛИВАЯ МОЛОДЕЖЬ РОССИИ»** программасы **СТИПЕНДИАТЫ БУЛДЫ**. Әлеге фонд Россиянең талантлы яшьләре потенциалын гамәлгә ашыру өстендә эшли. Алинәне котлыйбыз һәм аңа иҗат уңышлары телибез!

• • • •

1 ноябрь көнне ТРның Фәнни китапханәсендә **«ИДЕЛ БУЕНЫҢ КҮП МӘДӘНИЯТЛЕ МӘГАРИФ ПРОСТРАНСТВОСЫ: ИНТЕГРАЦИЯ ЮЛЛАРЫ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ»** исемле Халыкара конференция булды. Чараны Психология һәм белем бирү институтының күпмәдәниятле белем бирү һәм этнопедагогика лабораториясе оештырды. Конференциянең төп максаты – булган гамәли һәм теоретик тәҗрибәне гомумиләштерү, Идел буе төбәгендә күпмәдәниятле мәгарифнең үсеш-үзгәреш тарихын барлау.

• • • •

Шул ук көнне Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында **«ГЛОБАЛЬЛӘШҮ ШАРТЛАРЫНДА ЧАГЫШТЫРМА ТЕЛ БЕЛЕМЕ: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР»** конференциясе башланды. Әлеге фәнни форумда Россия, АКШ, Кытай, Төркия, Нидерланд, Испания, Йемен республикасы һәм Украина галимнәре, укытучылары һәм студентлары катнашты. Катнашучылар төрле илләрдәге урта һәм югары белем бирү системасы мәсьәләләре, тәрҗемә итү үзенчәлекләре, төрле структуралы телләрне өйрәтү методикасы турында инглиз һәм рус телләрендә сөйләштеләр.

• • • •

Шушы көннәрдә **ЯР ЧАЛЛЫ** институтының социаль-гуманитар бүлек **СТУДЕНТЛАРЫ** берничә юнәлеш: политология һәм психологияне берләштергән **КАТНАШ ДӘРЕСТӘ** «Хәзерге Россия җәмгыятенең сәяси мәдәнияте» темасына дискуссия оештырып, фикерләрен уртаклаштылар.

• • • •

1 ноябрьдә КФУда Европа университетлары профессорлары **МИХАЭЛЬ КАЙДИНГ** һәм **МАРИУШ СИЕЛЬСКИЛАРНЫҢ** Европа союзының эшчәнлегенә багышланган **АЧЫК ЛЕКЦИЯЛӘРЕ БАШЛАНДЫ**. Дәресләр инглиз телендә Европа укыту методикасына нигезләнеп алып барылды. Лекцияләр укытучы сөйләменнән генә торган монолог буларак түгел, ә студентлар да катнаша торган интерактив әңгәмә формасында узды.

• • • •

Шушы көннәрдә университетка **АВСТРИЯ** һәм **ФРАНЦИЯНЕҢ** яшь җәмәгать эшлеклеләреннән торган **ДЕЛЕГАЦИЯ КИЛДЕ**. Визит «Яңа буын» программасы кысаларында ясалды. Кунаклар университетыбызның Тарих музее, А.М.Бутлеров ис. химия институты, Физика институты, ИТИС югары мәктәпләре белән танышты. Тышкы элемтәләр департаменты директоры А.Крылов делегациягә КФУның эшчәнлеге, Австрия һәм Франция вузлары белән хезмәттәшлек турында сөйләде.

• • • •

1 ноябрьдә Кытайда ел саен үткәрелә торган «China Education Expo 2013» Халыкара күргәзмәсе кысаларында **ХАЛЫКАРА БЕЛЕМ БИРҮ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ АЧЫЛДЫ**. Чараның төп темасы итеп, Кытай һәм Россия арасында үзара студентлар алмашы мәсьәләләре сайланган. Конференция кысаларында КФУ турындагы презентация белән Тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов чыгыш ясады. Проректор шулай ук Кытай студентларының КФУдагы эшчәнлеге турында да сөйләде.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Ректорат



Влад Михневский фотосы

# Мәгълүмати диварлар булдырачакбыз!

Алинә САДЫЙКОВА

5 ноябрь көнне КФУның чираттагы ректорат утырышы узды. Аны ректор И.Гафуров алып барды.

Иң элек ул ректорат вәкилләренә КФУның конкурентлылыгын арттыру буенча «Юл картасы»н яклау, аның комиссия тарафыннан хуплануы турында сөйләде. Аның кабул ителүе университеттан күп үзгәрешләр таләп итәчәк. **Илшат Гафуров** фикеренчә, беренче чиратта, бу белем бирү системасында яңа юнәлешләрне тормышка ашыру белән бәйле булырга тиеш. Шуңа күрә ул гомуми курсларга оцифровка ясатырга әмер бирде. Шулай ук һәр фән буенча уку төркемнәрен барларга, институт директорлары һәм җитәкчеләреннән укыту нагрузкасын алып, 0,25 ставкага калдырырга кирәк, дип әйтте. Боларның студентларга уңай шартлар булдыру өчен эшләнгәненә басым ясады. «Студентка белем бирү белән бергә, без тормыш үзгәрешләренә җайлаша ала торган шәхесләр тәрбияләргә тиеш!» – дип билгеләде ректор.

Алга таба контроль йөкләмәләр үтәлеше һәм атналык чаралар планы хакында административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **Андрей Хашов** җиткерде. Проректор 12 ноябрьдә Күзәтүчәнлек советы утырышы булачагын һәм теләк-тәкъдимнәрне тиз арада хәбәр итәргә кирәклеген әйтте.

КФУның Юридик факультет деканы **Илдар Тарханов** җәй көне фаҗигале рәвештә һәлак булган профессор М.Челышев истәлегенә багышлап мемориаль такта ачу ниятен белдерде. Ректорат вәкилләре бу фикерне хуплады һәм әлеге тактаны профессор җитәкләгән кафедра янында эләргә дигән нәтиҗәгә килде. Бу идеяне яклап, И.Гафуров һәр структур бүлектә университетыбызның танылган галимнәре, данлыклы кешеләре турында мәгълүмати язмалар булдырырга тәкъдим итеп: «Аларны бина коридорларының, аудиторияләрнең диварларында булдыру безне тарихка тагын да якынайтачак», – диде.

Алабуга институты директоры **Елена Мерзон** үзенең структур бүлегендә Конфуций институтының Мәдәни үзәген булдыру идеясе белән чыгыш ясады. Аннан соң Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты директоры **Рамил Хәйретдинов**, үзе җитәкли торган структур бүлекнең бер укытучысы вакытыннан алда вафат булу сәбәпле, аның балигъ булмаган баласына 18 яше тулганчы пособие түләү тәкъдиме белән чыкты. Ректорат бу ике тәләкне дә бер тавыштан кабул итте.

Иң ахырдан ректор киңәшчесе – КФУның иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе **Юрий Алаев** университет сайтын алга җибәрү өчен башкарылган эшләр турында сөйләде. Әлеге мәсьәлә буенча ике киңәшмә уздырылган. Шуларның берсе сайтның төп битен үзгәртүгә бәйле булган. Ю.Алаев сүзләренчә, үзгәрешләр инде кабул ителгән һәм хәзер бары тик социологлар комиссиясен чакыртып, аларның фикерләрен генә беләсе калган.

Ректорат азагында И.Гафуров структур бүлек җитәкчеләренә кайчан һәм нинди конференцияләрдә катнашачаклары турында мәгълүматны бер ел алдан бирергә һәм һәр институтка презентацион материаллар, буклетлар әзерләп куярга кушты.

• Бездә кунак бар

# КФУ химия юнәлешен көчәйтә

Ләйсән ИСХАКОВА, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

5 ноябрь көнне КФУга О Клэрдагы Висконсин университеты (АКШ) профессоры Дэвид Эдвин Льюис килде. Кунак иң элек Казан университетының тарих музеенда булды. Аннары КФУ ректоры Илшат Гафуров Дэвид Эдвин Льюисны эш бүлмәсендә кабул итте. Әлеге өлешчә эшлекле, өлешчә дусларча очрашуда үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре күтәрелде.

Очрашуда, нигездә, Казан химия мәктәбе, әлеге мәктәпне булдыруда Казан университетының роле һәм КФУның бу юнәлештәге бүгенге үсеш программалары хакында сөйләштеләр. Сүзне **И.Гафуров** башлап җибәрде. «Россия фәннәрен бөтендөнья дәрәҗәсендә популярлаштыру КФУ өчен дә иң мөһим максатларның берсе булып тора. Шуңа Сезне университетыбызда күрү аеруча шатлыклы вакыйга», – диде ул сәламләү сүзендә. Казан химия мәктәбе кайчандыр Казан университетыннан үсеп чыгып, хәзерге заманда зур таралыш алды.

Бүген КФУда химия юнәлешен көчәйтүгә юнәлдерелгән программа кабул ителеп, тормышка ашырыла. Лабораторияләрне җиһазлау, өстәмә төзелеш эшләре алып барыла. Якын киләчәктә университетта сәнәгать химиясе бүлеге ачылачак. Ректор сүзләренчә, кабул ителгән программаның 80 процент өлеше интернациональләштерү, чит ил белгечләрен кызыксындыру мәсьәләләренә багышланган. И.Гафуров шушы шартларда чит ил партнерлары белән күрешеп аралашуның аеруча мөһим булуын билгеләп узды.

**Дэвид Эдвин Льюис**, үз чиратында, Казан химия мәктәбенең сәнәгать компанияләре белән үзара хезмәттәшлеге һәм бу хезмәттәшлекнең Арбузов, Крестовниковлар заманыннан ук дәвам итеп килүен искәртеп узды. Ул КФУның медицина химиясе юнәлешенең нәкъ менә Химия институтында үсеш алуын уңай күренеш буларак билгеләде. «Фән һәм гамәлнең бергә үрелеп баруы бик яхшы, чөнки Америкада медицина химиясе фундаменталь тикшеренүләрдән читләшкән хәлдә яши», – диде ул үз чыгышында.

КФУның химия өлкәсенә карата мондый зур игътибарын кемнәрдер тәнкыйть итә. Аны Казан химия-технология университетының дубляжы булачак, дигән гаепләүләргә каршы И.Гафуровның җавабы әзер: «Беренче дубляж булмаячак. КХТИ – урта белгечләр әзерләсә, КФУ топ-белгечләр, галимнәр әзерләү белән шөгыльләнәчәк. Конкуренция – үсешүзгәреш өчен менә дигән этәргеч!»

Казан университеты горурлыгының бер өлешен бөек фәнни ачышлар тәшкил итә. Алар арасында химия өлкәсенә караганнары да бар: Рутений химик элементын ачу (К.К.Клаус), органик кушылмалар төзелеше теориясен барлыкка китерү (А.М.Бутлеров).

«Яңа химик элементлар ачу – химияне ачу дигән сүз. Димәк, Казан университеты химияне ачкан», – диде Дэвид Эдвин Льюис.

Очрашу ахырында ректор кунакны Химия институтының яңа кампусы ачылышына чакырды. Аны киләсе елда, университетның 210 еллык юбилее вакытында ачарга җыеналар.

• Безнең канат

# Пушкин геройлары җанланды

Наталья ПАНКРАТОВА, 11 С сыйныфы

КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге лицей традицияләргә бик бай. Алар арасында иң кызыгы, иң серлесе – ел саен үткәрелә торган Пушкин балы!

Бу бәйрәмдә катнашкан һәркемне вакыт машинасы XVIII гасырга алып китә. Әйтерсең, син патша заманында яшисең. Синең тирәңдә купшы күлмәкле кызлар, фрак кигән егетләр. Аларның үз-үзләрен тотышлары да башка. Серле караш, оялчан елмаю... 1 ноябрь көнне безнең лицей шул чорга «кайтты». Казан Ратушасында Бах, Моцарт, Штраус көйләре яңгырады...

Быелгы Пушкин балы Александр Сергеевич Пушкинның Казанга килүенә 180 ел тулуга багышланды. Шуңа бәйле рәвештә, бәйрәм барышында бөек язучының иптәшләре Е.Баратынский, К.Фукс һәм аның хатыны А.Андреева белән очрашу мизгелләре сәхнәләштерелде. Бу төр чыгышларның барысын да РФнең атказанган һәм ТРның халык артисты Наилә Гәрәева әзерләде.

Балның беренче өлеше биюләргә багышланды. Һәр сыйныф аерым бию әзерләп, нәтиҗәдә уналты төрле искиткеч, берсеннән-берсе охшаган чыгыш тәкъдим ителде. Аларны әзерләүгә зур өлеш керткән, безне шул осталыкка өйрәткән лицеебызның талантлы хореографы Олег Романенконың җаланты алдында баш иябез. Беренче акт безнең чибәр кызларыбызның дефилесы белән тәмамланды.

Антракт вакытында барлык теләүчеләр үзләрен шагыйрь яки рәссам ролендә сынап карый алды. Моның өчен «Буриме» һәм «Дусларча шарж» түгәрәкләре эшләде. Яшь кызлар бик теләп чәчәк һәм җилләткеч телләрен өйрәнде. Өлкәнрәк туташлар күңеленә күбрәк балавыз белән багу хуш килде.

Кичәнең кульминацион ноктасы булып, «Бал королевасы» конкурсы тора. Анда унберенче сыйныфта укучы кызлар катнаша. Һәрелдагыча, бирәдә катнашучы туташларга карап, күзләр камаша. Үзләре чибәр, уңган, булган, биремнәрне югары дәрәҗәдә үтиләр. Һәр конкурсантка Пушкин әсәрләреннән бер героиня образын сайлап чыгыш ясарга кирәк иде. Шулай ук туташлар вальс бии белү осталыкларын да күрсәтте. Укучылар «Барышня-крестьянка», Татьяна Ларина, Наталья Гончарова, Мария Гавриловна, «Шамаханская царица», хәтта А.Пушкинның «Муза»сын да сайлаганнар.

Гүзәл затлар арасыннан жюри әгъзаларына иң-иңне аерып алу бер дә җиңел булмагандыр. Кызларның һәркайсы җиңүгә лаек, шуңа күрә аларга махсус номинация җиңүчеләре дигән дипломнар тапшырылды. Ә «Бал королевасы 2013» титулына 11 А сыйныф укучысы Арина Александрова лаек дип табылды. Арина таҗны ел дәвамында үзендә саклаячак һәм 2014 елда яңа королевага тапшырачак.

Кичә тәмам. Җиңүчеләр билгеле. Һәркем ел буена җитәрлек эмоция, күтәренке кәеф, рухи байлык алды. Безнең өчен шундый зур бәйрәм оештырган лицей җитәкчеләренә чиксез рәхмәтлебез.



Артур Мусин фотосы

**Тарих сәхифәләреннән**

Мәгълүматны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

# Ф.Бурнаш: «Сәйяр»ның мәгънәви әткәсе»

Бүген татарлар арасында театр сәнгате бик популяр. Авылларда, шәһәрләрдә һөнәри һәм үзешчән театрлар оеша, халык анда бик теләп йөри. Әмма, ни кызганыч, театрга нигез салучы шәхесләр хакында аз беләбез, белсәк тә, аларның иҗатын бәяләп бетермибез. Менә шундый бөек шәхесләр арасында «Сәйяр», «Нур» труппаларын оештыручы, режиссер, актер Габдулла Кариев шәхесе аерым урын тота. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә милли театрыбыз, башка театрлардан соң дөньяга килүгә карамастан, бик кыска вакыт эчендә югары дәрәҗәдәге сәнгать дөньясына әверелде.

Габдулла Кариев 1886 елның 8 маенда Татарстанның хәзерге Октябрь районы Күлбай-Мораса авылында Хәйрулла абзый гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында ала. Мораса элек-электән мәдрәсәсе, мәгърифәте белән тирә-якта дан тоткан. Габдулла Кариевның чын исеме исә Миңлебай Хәйруллин булган. Тәхәллүсе хакында төрле чыганак төрле мәгълүмат җиткерә. Г.Кариев үзенең исемен якын дусты Габдулла Тукайдан алган, дигән фаразлар бар. Ул шулкадәр зирәк бала була, 12 яшендә Коръәнне яттан өйрәнә. Мондый зирәк баланың «мужик» исеме белән Миңлебай дип йөртелүе авыл мулласы Зарифка бер дә ошамый. Ул үзенең яраткан шәкертенә Габдулла (Алла колы) исемен биргән, дигән фаразлар да яшәп килә. Фамилиягә килгәндә, Кариев еш кына «кари», ягъни Коръәнне яттан укучы кеше мәгънәсендә аңлатыла.



1904 елда Г.Кариев Җаек (Уральск) шәһәренә укырга китә. Монда ул, җырчы, сүз остасы, мәзәкче буларак, төрле әдәби кичәләрдә катнаша. Кариев – «Сәйяр», «Нур» труппаларын оештырган олы шәхес. Шул сәбәпле ул үзе дә һәрвакыт олы шәхесләр янында булган. Җаекта Г.Кариев татар халык шагыйре Габдулла Тукай һәм күренекле җырчы, җәмәгать эшлеклесе Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин) белән очраша һәм алар якын дуслар, фикердәшләр булып китәләр.

Беренче рус революциясе алды елларында Җаекта шәкертләр хәрәкәте башлана. Бу хәрәкәттә катнашкан 19 яшьлек Габдулла, шәкертләр хәрәкәте бастырылганнан соң, туган авылы Морасага кайта. Озак та үтми, Габдулланы эзләп, авылга полиция кешесе килә. Ләкин староста Габдулланы полициягә бирми, качырып калдыра. Соңыннан Габдулла, староста ярдәме белән, Хәйруллин фамилиясен Кариевка алыштырып, ялган паспорт ала һәм 1905 елның көзендә туган авылыннан тагын чыгып китә. Шулай итеп, үзенең таланты белән татар дөньясын таң калдырган Габдулла Кариев түбәннән, татар тормышының төбеннән күтәрелә.

> «Без шундый театр төзербез,
> аның исеме алтын
> хәрефләр белән
> язылыр»
>
> *Г. Кариев*

Артист Г.Камал әсәрләрендәге образларны аеруча яратып башкара. Ул әдәби әсәрдә сурәтләнгәннәр белән генә чикләнеп калмый, персонаж прототипларының психологиясен, гореф-гадәтләрен, үз-үзләрен тотышларын һәм сөйләшү үзенчәлекләрен өйрәнә. Шулар ярдәмендә җыелма образлар иҗат итә (Хәмзә («Беренче театр»), Әхмәтҗан («Бүләк өчен»), Сираҗи («Банкрот»), Мөхәммәтҗан Хафиз («Безнең шәһәрнең серләре») һ. б.)

Г.Кариев, репертуарны киңәйтү нияте белән, төрле язучыларга мөрәҗәгать итә. Ф.Әмирханның «Яшьләр» драмасын, азәрбайҗан язучысы П.Вәхиревнең «Мөсибәте Фәхретдин» исемле әсәрен сәхнәгә куя. Үзе дә «Артист» исемле комедия яза. 1917-1918 елларда Г.Кариев җитәкләгән «Сәйяр» труппасы М.Горькийның «Мещаннар», А.Чеховның «Чия бакчасы», М.Фәйзинең «Галиябану» һәм башка әсәрләрен сәхнәләштерә.

Язучы Г.Ибраһимов Г.Кариев турында: «Кариев өчен тормыш, дөнья, бәхет, сәгадәт юк, тик театр бар, шул театрны үстерү өчен, шуның белән көю бар иде», – дип язган.

Кызганыч ки, Г.Кариевка татар театрына бәйле барлык ниятләрен дә тормышка ашырырга насыйп булмый. Ул 1920 елның 28 гыйнварында Казанда тиф авыруыннан үлә. Нибары 13 ел гына милләткә, театрга хезмәт итсә дә, шушы еллар эчендә Г.Кариев профессиональ дәрәҗәдәге театр төзи. Театрның төрле өлкәләрендә мәктәп, традиция калдырган олуг зат ул.

## Игътибар, конкурс!

Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театры **Татарстан югары уку йортларында укучы студентлар арасында гаммәви мәгълүмат чараларында театраль сәнгать темасын (төгәлрәк, Г.Кариев, театр, Г.Кариев театры спектакльләре һәм актерлары турында) яктырту буенча конкурс игълан итә**. Бәйгедә җиңүчеләр Г.Кариев исемендәге стипендиягә лаек булачак. Конкурсның төп максаты: гаммәви мәгълүмат чараларында Г.Кариев исемендәге театр эшчәнлеген төрле яклап һәм объектив яктырту, театр турында позитив фикер булдыру, ММЧ ярдәмендә студентларның игътибарын дөнья театр сәнгатенең югары үрнәкләренә юнәлтү. Конкурс материаллары мәкалә, репортаж, интервью, очерк жанрларында тәкъдир ителергә мөмкин. Газета һәм журналда басылган язмаларның оригиналлары яки күчермәләре (басма материалның кайда һәм кайчан басылуы хакындагы өстәмә мәгълүмат белән) кабул ителә.

Телевизион сюжетларны (телевизион (радио) канал, тапшыру һәм аның эфирга чыгу вакытын күрсәтеп) dvd-video яки avi форматында видеойөрткечләрдә, аудиоматериалларны (эфирның адрес базасын күрсәтеп) mp3 яки wav форматында CD һәм DVD дискларда туплап бирергә кирәк булачак. Интернет материалларын кәгазьгә бастырылган (бастырылу датасын һәм URL-адресын күрсәтеп) рәвештә тапшыру зарур.

Конкурс материаллары тирән аналитика, бай мәгълүмат белән сугарылган, объектив, төгәл, аңлаешлы булырга тиеш. Жюри әгъзалары теманың оригиналь яктыртылуы, авторның стиле һәм сөйләм байлыгына да зур игътибар бирәчәк.

Конкурста катнашу өчен, **гариза һәм материаллар 1 июньнән Казан шәһәре, Гладилов ур., 49 йорт, 34 каб. адресы буенча кабул ителә**. (тел. 555-37-27; *e-mail: tattuz@pochta.ru*). **Нәтиҗәләр 2014 елның сентябрендә ясалачак**.

**Яшьлек–яңарыш**

# Алхимик кем ул?

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Алхимик кем ул? Ул ни белән шөгыльләнә? Бу һәм башкалар турында республиканың наркоконтроль хезмәткәрләре һәм 58нче кадет мәктәбе укучылары Г.Кариев ис. яшь тамашачылар театры сәхнәләштергән «Алхимик» спектаклен карагач белде.

Татарстан республикасында 16 сентябрь һәм 16 октябрь көннәрендә «Наркотикларсыз тормыш» акциясе узды. Бу зур чараны һәр ел саен, хокук саклау органнары белән берлектә, ТР прокуратурасы Татарстанның төрле министрлыклары һәм ведомстволары оештыра.

Әлеге акциядә Г.Кариев ис. татар дәүләт яшь тамашачылар театры да актив катнашты. Кариевлылар, П.Коэльоның «Алхимик» (Ф.Янышева һәм Р.Әюпов инсценировкасы) спектаклен сәхнәләштереп, Татарстан районнары һәм Казан шәһәренең урта һөнәри белем бирү учреждениеләре, көллиятләре студентларына тәкъдим итте. Спектакльне Балтач, Кайбыч, Кама Тамагы, Югары Ослан районнарында яшәүче яшь тамашачылар да карау бәхетенә иреште.

30 октябрь көнне Г.Кариев ис. яшь тамашачылар театрында «Наркотикларсыз тормыш» акциясенең йомгаклау этабы булды. Кариевлылар сәхнәләштергән «Алхимик» спектаклен карарга республиканың наркоконтроль хезмәткәрләре һәм Казан шәһәренең 58нче кадет мәктәбе укучылары да килгән иде.

Театр директоры Мансур Зиннур улы Ярмиев билгеләп үткәнчә, бу спектакль быелгы акция кысаларында уникә тапкыр сәхнә тоткан, аны биш меңнән артык тамашачы караган. «Әгәр шул биш меңнең яртысы гына булса да наркотикларның нинди куркыныч афәт икәнен аңласа, без бик шат булыр идек», – диде Мансур Зиннур улы. Әлеге акциядә актив катнашканнары өчен, тетар артистлары наркоконтроль хезмәткәрләре тарафыннан Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Спектакль наркотиклар куллану аркасында үлем белән яшәү арасында калган яшь егет тормышы турында сөйли. Яшьләр көн саен диярлек бер ишек алдына наркотик кабул итәргә җыелалар. Төп герой Илдус та, дуслары сүзенә карап, шул яман гадәтне үз итә. Һәм көннән-көн кешелек сыйфатларын югалта бара. Көннәрдән бер көнне дозаны арттыра һәм яшәү белән үлем арасында кала. Шул вакытта аның кулына фәлсәфи тормыш сурәтләнгән китап килеп керә. Аның җаны шул китаптагы тормышка эләгә.

Илдус Испаниягә барып чыга һәм анда Сантьяго исемле егет белән таныша. Ике дус бик зур сынаулар аша үтә. Сәяхәт вакытында, Илдус наркотикларсыз тормышка кайтырга теләвен аңлый. Дустына: «Әти-әнием мәдрәсәдә укуымны теләделәр, ә мин аларның ышанычын аклый алмадым. Яңадан минем белән горурлануларын телим», – ди. Шулай ук аның аңында сөекле кыз образы туа. Ул начар гадәтләрдән арынырга теләвен аңлый, үзендә моңа көч таба һәм бөтенләй башка – киләчәккә уй-хыяллары булган кешегә әверелә.

Реаль тормышка кайткач, ул янә наркоман дуслары компаниясенә эләгә. Алар Илдусның исән калуына сөенә. Тамаша Илдусның дусларын наркотиклардан арындырырга теләвен, яман гадәтләрдән башка яшәүнең тагын да рәхәтрәк икәнен аңлатырга тели.



Спектакльдән бер күренеш.

Тамаша яшь буын аудиториясен күздә тотып эшләнгән. Шуңа да аның тәэсир көче зур. «Алхимик» тормыш мәгънәсе һәм кыйммәтләре турында уйланырга мәҗбүр итә.

Татарстан Республикасының антинаркотик комиссиясе карары нигезендә, спектакль 2008 елдан бирле республика һәм район киңлекләрен гизә. Чираттагы спектакльдә баш рольләрне Илнар Низамиев һәм Зөлфәт Гәрәев башкарды. Сәхнә бизәлешенә, костюмнарга, актерларның уйнавына тел-теш тидерерлек түгел. Сәхнәдә һәр хәрәкәт, һәр деталь уйланылган. Спектакльдә уйнаучы актерларга бик җаваплы бурыч йөкләнгән иде һәм алар бу миссияне югары дәрәҗәдә башкарып чыкты.

• Алар бездә укыган

# Рөстәм Галиуллин: «Миңа бәйсез булу ошый»

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Журналист иҗатының кызыклы ягы, минемчә, һәрдаим хәрәкәттә булуда, төрле кызыклы шәхесләр белән аралашып торуда. Шушы көннәрдә «Идел» яшьләр журналы баш мөхәррире, безнең университетны тәмамлаган Рөстәм Галиуллин белән очраштык. «Идел» журналының бүген үз кыйбласы бар. Укучылары да даими, тиражы тотрыклы. Коллективта да дустанә мөнәсәбәт хөкем сөрә. Боларның барысы да җитәкчедән тора.

**– Сез язучылык, журналистика өлкәсенә ничек килеп эләктегез?**

- Барысы да 9 сыйныфта татар әдәбиятыннан район олимпиадасында җиңүдән башланып китте. Мин бөтенләй дә бу юлдан китәргә тиеш түгел идем. Кечкенәдән икътисад, математика-физика өлкәсенә кереп китәрмен дип уйладым. Унберенче сыйныфта укыганда, район газетасыннан шалтыратып, журналистика юлын сайларга тәкъдим итүләре дә хәтеремдә. Ә мин ул вакытта Төзелеш институтының «Икътисад» бүлегенә укырга керергә әзерләнеп ята идем. Кызык өчен генә документларымны КДУның татар журналистикасы бүлегенә һәм татар филологиясе бүлегенә тапшырдым. Нәтиҗәдә татфакны сайладым. Ләкин, анда кергәч тә, мин язучы булырмын, журналистикага кереп китәрмен дип уйламадым. Беренче көннән үк университеттагы «Әллүки» иҗат берләшмәсенә эләктем. Кердем, ниндидер хикәяләр, шигырьләр тикшереп утыралар. Уйладым да, карале, мин дә болай гына яза алам бит әле дип, үземнең хикәяләремне тәкъдим иттем. 2 атнадан бу хикәяләр «Сабантуй» газетасында басылып та чыкты. Беренче гонорар шундый зур стимул булды ки, беренче китабым бик тиз арада язылып та бетте. 2007 елда «Иделем акчарлагы» конкурсында гран-прига лаек булып, бу өлкәгә очраклы гына килмәгәнемне аңладым. «Шәһри Казан» газетасында эшләү дә минем өчен бик зур мәктәп булды.



**- «Идел»дә нинди темаларга һәм жанрларга өстенлек бирәсез?**

- «Идел», беренче чиратта, яшьләр журналы. Димәк, үзеннән-үзе яшьләр темасы дигән сүз. Икенчедән, «Идел» - әдәби журнал. Димәк, өстенлекне проза белән поэзиягә бирәбез. Үзем прозаик буларак, повесть һәм хикәяләрне күтәп алам. Шигърият көчле, шагыйрьләребез күп, ә менә проза аксабрак тора. Безне, яшьләргә ни кызык, шул кызыксындыра.

**- Язучы күп язарга тиешме? Язучының дәрәҗәсе ни белән билгеләнә?**

- Кеше көн саен нәрсә дә булса язарга тиеш. Иң дөресе шул. Ләкин мин үзем сан белән сыйфатны аерып куям. Каләм тутыкмасын өчен, һичьюгы көндәлек алып барырга тырышам. Кешегә кайвакыт тарихка кереп калу өчен, бер әсәр дә җитә. Ә журналистларга килгәндә, алар, һичшиксез, көн саен язарга тиеш. Шул ук вакытта жанрлар төрлелеге дә сакланырга тиеш. Аннан егет кеше 30 яшькә кадәр кимендә 3 тапкыр эш урынын алыштырырга тиеш. Бер урында катып калу стимулны киметә. 3 ел «Шәһри Казан» газетасында утыру миңа бик җитте.

**- Ә хәзер эш урыныгызны үзгәртер идегезме?**

- Әлбәттә, андый теләк бар. Урын өчен курка торган кеше түгелмен. Үземне эшмәкәрлектә дә сынап караганым бар. Бүген үзеңне бөтен өлкәдә дә сынап карарга була. Хәзер мөмкинлекләр дә җитәрлек. Моның уңай ягы да, тискәре ягы да бардыр, әлбәттә.

**- Сезнең үзегезне укытучылык эшендә сынап караганыгыз бармы?**

- Без әти ягыннан укытучылар нәселе. Әнием укытучы иде, ике апам укытучылар иде. Мине өйдә укытучы булма дип үстерделәр. Әле дә хәтеремдә, 3-4 курста мәктәпкә практикага җибәрделәр. 8 сыйныф кызлары. Шәһәр кызлары шук була бит инде, күз кысып утыралар. Түзмәдем, директор бүлмәсеннән «Шәһри Казан» мөхәрриренә шалтыратып, алып китүләрен сорадым. Шуннан укытучы була алмавыма, моңа теләгем дә юклыгына төшендем. Ләкин, уйлап карасаң, укытучы - яхшы һөнәр, укытучы булган кеше бар өлкәдә дә уңышка ирешә ала.

**- Сезгә килгән хикәяләрдә, хатларда яшьләрнең тел ярлылыгы сизеләме? Әллә киресенчәме?**

- Күп хатлар бүген Башкортстан якларыннан килә. Аларның теле бик ошый миңа. Ни генә әйтсәк тә, бүген татарчабыз-русчабыз кушылып бетте бит инде. Телебез бүген актив үзгәрә, аны берни эшләтеп тә булмый. «Идел»нең максаты - әдәби телебезне саклау.

**- Сез үзегезне әрсез дип саныйсызмы?**

- Мине алдап булмый, барыбер үземнекен итәм мин.

**- Беренче хикәягезне кайчан яздыгыз?**

- 16 яшьтә. Мин укырга 6 яшьтә кердем. 21 яшьтә укуын тәмамлаган, 3-4 еллык стажлы, бәллүр каләмле, китабы чыккан, фатиры, машинасы булган кеше идем инде (мактанып әйтүем булмасын). Мин беренче курста укыганда ук, өйдән акча алмадым. Миңа бәйсез булу ошый иде.

• Әдәп-әхлак

Кеше, дөньяга килеп, бераз вакыт үтүгә, үзенчә нидер әйтергә омтыла башлый. Кечкенә кешенең иң беренче әйткән сүзләре «әннә», «мәммә», «мә» кебек сүзләр. Үсә-үсә сүзлек запасы байый, адәм баласы күп сүзләр белә башлый, ягъни сөйләшергә өйрәнә. Ә кешенең нинди сүзләр белән сөйләшүе гаиләдән, әти-әнидән, тәрбиядән килә.

# Җылы сүз – җан азыгы

**Гөлия ИМАМОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Бер-берсенә хөрмәт, ихтирам, игътибар булган гаиләдә үскән балалар әти-әниләренең бу сыйфатларын үзләренә сеңдерәләр. Бер фикерне күптөрле сүзләр белән һәм төрлечә тәэсир итәрлек итеп әйтергә мөмкин. Тәрбияле кеше хәтта кайгы-хәсрәтне, күңелсез хәбәрне дә кешенең хәтерен калдырмаслык сүзләр белән җиткерә белә.

Безнең татар халкында «Кеше сүзе кеше үтерә» дигән мәкаль яши. Бу мәкаль сүзнең тормышыбызда зур роль уйнавын күрсәтә. Кирәк-кирәкмәс урында сүз сөйләү, гайбәт һәм яла ягу, дөрес икәнлеге шикле булган фактлар турында сөйләү, бер кеше сүзен икенчесенә җиткерү – болар барысы да сүзнең тискәре тәэсирен күрсәтә торган мисаллар.

Сүзләрне дөрес сайлап сөйләшү кешенең белем дәрәҗәсенә һәм тормыш тәҗрибәсенә дә бәйле. Зыялы, тәрбияле кеше талашып, ямьсез сүзләр әйтеп йөрми. Тормыш тәҗрибәсенә ия булган өлкән буын вакилләре, гадәттә, сүзләрен уйлап, үлчәп, күңелләрне яраламаслык итеп җиткерә беләләр. Халкыбызның «Җиде кат үлчә, бер кат кис» мәкале сүзне уйлап, үлчәп, кирәклесен генә әйтү зарур икәнен искәртә.

Кешеләр арасында кайчагында бик ямьсез сүзләр әйтешүнең шаһиты буласың һәм шунда уйланасың: бу кешеләр яңадан бер-берсенең күзләренә ничек күтәрелеп карарлар икән? Ямьсез сүз әйткән кеше үзе дә ямьсез күренә бит ул. Шуңа күрә мин үземнең әйләнә-тирәдәге кешеләргә, бигрәк тә әти-әниемә, туганнарыма, укытучыларыма һәм төркемдәшләремә начар сүзләр әйтмәскә тырышам. Кайвакыт, ачуым килсә дә, эндәшми калам. Татар халкының тагын бер акыллы мәкале: «Авыздагы сүзгә син ия, авыздан чыккач, сүз ия», – ди бит.

Бу дөньяда бер генә яшибез. Үзеңнән соң матур истәлекләр калдырыйм дисәң, кешеләрнең йөрәген яраларлык сүзләр әйтмә!

• Аклы-каралы дөнья

# Дусмы? Әллә?..

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Супер-пупер... Интернет! Алтын көзнең бер көнендә Россиядә Бөтендөнья Интернет көне билгеләп үтелде. Бүгенге тормышны Интернеттан башка күз алдына китереп буламы икән?



Юктыр... Чөнки Интернет бер көн генә булмаса да, кеше үз-үзен кая куярга белми, төшенкелеккә бирелә башлый. Интернет белән безнең тормыш шундый тыгыз бәйләнгән ки, хәзер инде аңардан башка укып та, эшләп тә, яшәп тә булмый кебек... Ләкин интернеттан дөрес итеп файдалана белергә өйрәнергә кирәк. Кыска вакыт эчендә аннан файдалы мәгълүмат алырга теләсәгез, язмадагы биш серкиңәш нәкъ сезнең өчен!

***1. Ике тапкыр икең – дүрт.*** Ә бәлки йөз кырык дүрттер? Әгәр син андагы һәр сүзгә ышансаң... Интернет – мәгълүмат белән тәэмин итүче чыганак кына түгел, ә үзенекен эшләп, файдаланучыларны шаяртып алырга яратучы «әфәнде» дә. Шуңа күрә биредәге һәр мәгълүматның дөреслеген тикшерергә кирәк.

***2. Мине «суырды» бугай.*** Интернетта озак утырсаң, сине монитор «суырып» алырга да бик мөмкин. Дуслар белән йөреп, күңел ачып кайтыр урынга, син җансыз тартма белән вакыт уздырасың.

***3. Ә нәрсә кирәк иде соң әле миңа?*** Компьютерыңны нәрсәгә кабызганыңны онытып, көне буе монитор каршында утырып та була. Социаль төркемнәргә теркәлгән булсаң, бигрәк тә...

***4. Кая китә вакыт дигәннәре?*** Вакытны бушка уздыру – бик куркыныч әйбер. Монитор почмагында урнашкан сәгатькә карап алу – шушы «авыру»дан котылуның иң әйбәт юлы. Шул очракта Интернетта утырырга да, башка эшләргә дә вакытың җитәр!

***5. Анда бар да бар.*** **Бар барын.** Ләкин Интернет иҗатка да, кызыклы китапларга да көндәш була алмый. Дөрес, андагы һәр әйбердән тиешле урында һәм тиешле вакытта файдалансаң, син заманадан бер адым алда барасың, дигән сүз.

Интернетны кулланып, үзебездән ерак булган дусларыбыз белән аралашырга, кызыклы һәм мавыктыргыч мәгълүмат, яңалыклар эзләргә була. Ләкин үзегезнең реаль тормышта яшәвегезне, сезне ничек бар, шулай яратучы дусларыгыз бар икәнлеген онытырга ярамый. Һәм иң мөһиме: Интернет – ул бары тик мәгълүмат чыганагы. Ә кеше – йөрәге булган җан иясе!

*- Ә безнең интернет лимитсыз, җитмәсә, аның өчен акча да түләмибез.*
*- Ничек алай?*
*- Әй, әти тырышты инде. Безне Интернетка тоташтырганда, әти өстә яшәүче күршеләребез белән сөйләшеп куйган. Янәсе, ул уртак булачак, акчасын бүлеп түләячәкбез. Сез – җәп айларда, ә без так айларда түләрбез, дигән.*
*- Ә ни өчен бушка дисең?*
*- Соң ул астагы күршеләр белән дә шулай ук килешкән. Алар так айларда түләсә, безгә җәп айлар кала инде.*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.